ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.18а, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 18а йорт, Кече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 4** **01 ноябрь 2021 ел**

«Ютазы муниципаль районы Биек Тау авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карары, Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 12 ноябренә 14.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Биек Тау торак пунктында Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Биек Тау бистәсе, Тынычлык ур., 26 адресы буенча урнашкан бина янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Биек-Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булмаган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

-Хуҗалык инвентаре өчен бина төзү, зиратка киртәләр урнаштыру (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, транспорт чыгымнары).

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

"Ташкичү авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы Р.К.Вәлиев